**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШЛЫГЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт,

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail:balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2015 Балык Бистәсе штп. №156пг

Территориаль-тармак килешүе проектын әзерләү, төзү һәм килешүнең үтәлешен контрольдә тоту буенча күмәк сөйләшүләр алып бару өчен тармак комиссиясе эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләре турында

2013-2015 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы һәм Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика комитеты арасында территориаль-тармак килешүе срогы чыгуга бәйле рәвештә, территориаль-тармак килешүе проектын әзерләү, төзү һәм килешүнең үтәлешен контрольдә тоту буенча күмәк сөйләшүләр алып барганда эш бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итү максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 33, 36 статьялары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2016-2018 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы һәм Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан республика комитеты арасында территориаль-тармак килешүе проектын әзерләү, төзү һәм килешүнең үтәлешен контрольдә тоту буенча күмәк сөйләшүләр алып бару өчен тармак комиссиясе эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләрен түбәндәге составта билгеләргә:

Вәлиев Илһам Госманович – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы;

Исмәгыйлев Рафаэль Дәүләтьярович – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе;

Шелкова Светлана Александровна – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килешенү буенча);

Миндубаев Илдар Илдусович – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлегенең баш белгече;

Ногманова Илсия Мәликовна – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

И.Г.Вәлиев